БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 01 2020 ел № 47

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне планлаштыру һәм муниципаль берәмлек территориясен ызанлау проектларын әзерләү турында**

2004 елның 29 декаберендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне планлаштыру һәм муниципаль берәмлек территориясен ызанлау проектларын әзерләргә.

2. Расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне планлаштыру һәм муниципаль берәмлек территориясен ызанлау проектларын әзерләү буенча эшләр башкару тәртибе һәм вакытлары (1 нче кушымта).

2.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне планлаштыру һәм муниципаль берәмлек территориясен ызанлау проектларын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының http:/baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 30.01
47 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне планлаштыру һәм муниципаль берәмлек территориясен ызанлау проектларын әзерләү буенча эшләр башкару тәртибе һәм вакытлары

| т/б № | Чаралар исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | Территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектларын әзерләү |
| 2. | Комиссия тарафыннан территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектларын район башкарма комитетына җибәрү |
| 3. | Район башкарма комитеты тарафыннан территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектларын тикшерү һәм аны Чепья авыл җирлеге башлыгына җибәрү; проект таләпләргә һәм документларга туры килмәгән очракта - аны комиссиягә эшләп бетерү өчен җибәрү |
| 4. | Территорияне планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектлары буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итү |
| 5. | Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырып чыгару |
| 6. | Кызыксынган затлар тарафыннан комиссиягә проект буенча тәкъдимнәр җибәрү |
| 7. | Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү процедурасын тәмамлау |
| 8. | Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан проектка үзгәрешләр кертү |
| 9. | Чепья авыл җирлеге башлыгына гавами тыңлауларның беркетмәләре һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә белән проект җибәрү |
| 10. | Чепья авыл җирлеге башлыгы тарафыннан Балтач муниципаль районы Советына раслау өчен проект җибәрү |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның 30.01 _________
47 _______ номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектларын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссиягә җибәрү тәртибе

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру һәм территорияне ызанлау проектларын әзерләү буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәре түбәндәге адресларга җибәрелә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына 422250, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач штп. , Ленин урамы, 42 нче йорт, 118 нче кабинет адресы буенча.

- Чепья авыл җирлеге башкарма комитетына 422243, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Чепья авылы, Ленин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча.

Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

- мөрәҗәгать җибәрүченең адресы;
- элемтә өчен телефоннар;
- юридик затның исеме; җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (юридик затлар өчен);
- юридик зат булып оешмаган физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме.

Мөрәҗәгатьтәге тәкъдимнәр логик рәвештә бәян ителгән һәм мотивацияләнгән булырга, текст А4 форматындагы кәгазьдә язылган, укырга уңайлы булырга тиеш.